# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында» 1993 елның 20 октябрендәге 1991-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, № 1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 3; 2000, № 12 (11) (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 7 статьяда:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәҗбүри медицина иминләштерүенә эш бирүчеләр тарафыннан түләнә торган кертемнәр, шулай ук эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә кертемнәр федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.»;

икенче, өченче һәм дүртенче өлешләрне төшереп калдырырга;

бишенче һәм алтынчы өлешләрне икенче һәм өченче олешләр дип санарга;

өченче өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Ихтыярый медицина иминләштерүе кертемнәре яклар килешүе буенча билгеләнә.».

2. 8 статьяны төшереп калдырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 21 ноябре
№ 1191